Государственное автономное профессиональное образовательное учреждение «Мамадышский политехнический колледж»

УТВЕРЖДАЮ
Зам. директора по ТО
__________ В.В.Файзреева
«01» сентября 2023г.

# ФОНД ОЦЕНОЧНЫХ СРЕДСТВ

для проведения текущего контроля и промежуточной аттестации
по учебной дисциплине
ОД.14 Родной язык (татарский)
для специальности
43.02.15 Поварское и кондитерское дело

Мамадыш
2023

Фонд оценочных средств разработан на основе рабочей программы и примерного фонда оценочных средств по общеобразовательной дисциплине «Родной язык (татарский)» и в соответствий с Федеральным государственным образовательным стандартом среднего общего образования (приказ Министерства образования и науки РФ № 413 от 17 мая 2012 г., зарегистрировано в Минюсте РФ №24480 от 07 июня 2012 г. (с изменениями и дополнениями от 12 августа 2022г.))

Обсуждена и одобрена на заседании предметно-цикловой комиссии общеобразовательных дисциплин

Разработала преподаватель:
_______________ Р.Н.Кашапова

Протокол № 1
«28» августа 2023 г.
Председатель ПЦК ___________ Н.С.Порываева

# Эчтәлек

**Тема1.1.Тел – аралашу чарасы, иҗтимагый һәм сәяси күренеш.**
**Тема 2.1. Фонетика.**
**Тема 3.1.Сүз төзелеше һәм ясалашы.**
**Тема 4.1.Лексикология.**
**Тема 5.1. Морфология.**
**Тема 6.1.Татар әдәби теленең функциональ стильләре.**
**Тема 7.1. Синтаксис.**
**Тема 7.9. Текст.Туры һәм кыек сөйләм.**

**Практик эш №1.** Сорауларга җавап бирергә һәм тәрҗемә итәргә
Что ты любишь больше всего?
Как ты жаришь картошку?
Чем ты режешь хлеб?
Как ты варишь компот?
Когда ты собираешь ягоды?
Как ты варишь варенье?
Какое мясо ты любишь?
Какой суп ты любишь?
Какую кашу ты любишь?
Любишь ли ты лапшу?

**Практик эш №2**

Беренче баганада – мәкальләрнең башы, икенче баганада - ахыры. Дөрес “пар”ларын табып, русчага тәрҗемә итәргә кирәк.

| | |
|---|---|
| 1.Ипи-тоз, | тураган белер. |
| 2.Аштан олы | ачуы яман. |
| 3.Ач кешенең | хөрмәтле йорт. |
| 4.Ашаган белмәс, | якты йөз. |
| 5.Кеше ашы | бозмас. |
| 6.Май ботканы . | тәмле була. |
| 7.Кунаклы йорт- | кире ябышмас. |
| 8.Кискән икмәк. | булып булмый. |

(1.Ипи-тоз,якты йөз
2.Аштан олы булып булмый
3.Ач кешенең ачуы яман.
4.Ашаган белмәс,тураган белер.
5.Кеше ашы тәмле була.
6.Май ботканы бозмас.
7.Кунаклы йорт-хөрмәтле йорт.
8.Кискән икмәк кире ябышмас. )

**Практик эш №3**

Иҗекләрдән файдаланып шигырь юлларын язарга.

Һәр ,ипи ,кемгә,кирәк!
Ипи, көн дә ,һәм,кирәк!
Космонавтка да,ипи
Да. кирәк,очучыга.
Кирәк,ипи,сезгә,дә!
Кирәк,ипи,дә,безгә дә_
Кирәк,һәммәбезгә ,дә!

( Һәркемгә ипи кирәк!
Һәм көн дә ипи кирәк!
Ипи космонавтка да,
Очучыга да кирәк.
Ипи сезгә дә кирәк!
Ипи безгә дә кирәк_
Һәммәбезгә дә кирәк!)

**Практик эш №4. Ризык исемнәрен язарга.**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| О | н | | | | | | |
| Ч | ә | й | | | | | |
| Ө | й | р | ә | | | | |
| Б | о | т | к | а | | | |
| Ч | ә | к | ч | ә | к | | |
| Э | р | е | м | ч | е | к | |
| К | ы | с | т | ы | б | ы | й |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| А | ш | | | | | | |
| И | п | и | | | | | |
| Т | о | р | т | | | | |
| К | ү | м | ә | ч | | | |
| Д | у | ч | м | а | к | | |
| Г | ө | б | ә | д | и | я | |
| Ө | ч | п | о | ч | м | а | к |

**Практик эш №5. Бирелгән текстка сораулар төзергә.**

**Татарларда чәй ашамлыклары**

Татарлар чәй яраталар.Күп әбиләр чәйне шикәр белән эчәләр.Кайбер кешеләр өрек, как, яисә лимон белән эчәргә яраталар.Ә кайберләре чәйгә сөт, я каймак салалар.

Чәй кайнар,хуш исле булырга тиеш.Чәйне матур чынаякка салып эчсәң,тагын да яхшырак була.

Чәй янына баллы пирог,талкыш кәләвәсе, чәкчәк, бавырсак, кош теле пешерәләр.

**Практик эш №6** Сорауларга җавап бирергэ.

**1.Бу җөмләләрне тәрҗемә итәргә һәм икмәккә карата үз фикереңне әйтергә.**

Икмәк - тормыш тоткасы. Икмәк - һәр табынның күрке. Икмәк-туклык, сәламәтлек, хезмәт, шатлык, муллык , бәхет билгесе.

**2. Шигырьне укып чык. Бу юлларның авторы кем һәм шигырь ничек атала? (Г.Тукай "Эш")**

Иртә торгач та язарга,дәрсең укырга тотын.
Тынма,эшлә,торма тик,тынсаң,тынарсың җомга көн.
Күр,ничек эшли кояш: иртә тора,таң аттыра,
Көнозын күктә йөзә һәм көн буенча яктыра.
Син кояштан үрнәк алсаң,иҗтиһад итсәң һаман,
Күп арасында кояш күк ялтырарсың бер заман!

**3.Сез татар халкының нинди таба ашларын беләсез?Үзең яраткан бер ризыкны әзерләү турында сөйлә.**

(Камыр ашларының төрлелеге - традиңион табынның үзенчәлеге булып тора.Таба ашларына барысыннан да элек ипи керә, әче камырдан әзерләнгән кабартма, коймак иң борынгы ризыклардан: кыстыбый,бәлешләр, өчпочмак,пәрәмәч,бөккән, тәкә, гөбәдия; татлы камыр ашларыннан: катлама,кош теле, ләвәш,чәк-чәк,бавырсак – татар халкының иң хөрмәтле ашлары.)

**4.Сезгә ризыкны әзерләү компонентлары бирелә. Ризыкның исемен әйтегез һәм ясау тәртибен сөйләгез.**

Камыр -900-1000 г.
Әзер тура – 250 г.
Дөге -300 -400 г.
Йөзем- 250- 300 г.
Йомырка -1 дистә
Кайнатылган сөт -350- 400 г.
Тоз,таба майларга май -50 г.

**Практикэш №7. Тәрҗемә итәргә**

Молочный суп,суп с лапшой,гороховый суп,рисовая каша,гречневая каша,чай с молоком,жареный картофель,варёная рыба,мясной бульон,куриный бульон,яблочный компот,пирожки с капустой,рыбные котлеты.

**Практик эш №8.**

**1.Г. Исхакый “Сөннәтче бабай” әсәреннән өзек тыңлана ,төшеп калган сүзне табарга. Тәрҗемә итәргә.**

“Өйләрендә әллә никадәр җиһазлар булмаса да,җәмәгатьләре шул карт-карчык берлән бетсә дә, Гөлйөзем әби көн буе эштән бушамый иде.Ул кайвакытлар мич ягып күмәч сала,... пешерә,бәйрәм көннәрендә картының намаздан кайтуына коймак хәзерләп куя иде.”(коймак )

2.Шигырьне укырга,тэржемэ итэргэ хэм исемен атарга.

Кем иң эшчән, кем иң тырыш –ул булыр!

Азрак сөйләр,ә хезмәте мул булыр.

Кем иң юмарт,кем иң гадел –ул булыр!

Үзе гади,ә табышы мул булыр.

Кем иң сабыр,кем иң түзем – ул булыр!

Ул булганда ил табыны мул булыр! (игенче )

Энже Мөэминова.” Игенче”.

3.Бәрәңге белән пешерелә торган татар халык ашы кыстыбыйны барыбыз да беләбез. Кыстыбыйның икенче исеме ничек? ( Җавап: күзикмәк.)

4. Гомәр Бәширов “Туган ягым – яшел бишек “ әсәреннән өзек тыңлана ,төшеп калган сүзне табарга. Тәрҗемә итәргә

“... Берсе артыннан берсе икешәр,өчәр,дүртәр булып керә торалар,күчтәнәч алып чыга торалар.Якынлыкларына карап,әни аларның кечкенә капчыкларына я йомырка,я кызыл билле прәннек,я ... салып чыгара .Туган – тумача ,кардәш-ыруга кергәндә,үзеңә дә шундыйрак күчтәнәч бирәләр...” ( Гомәр Бәширов “Туган ягым – яшел бишек “.)Я нәрсә салып чыгара? (ак төш)

**Практик эш №9.** Место точек поставьте нужные буквы.

а) К..ләм, мәк...лә, сәнг...ть, иг..тибар, г..рәп, дикък...ть, һәр...яклы, ел..язма, яшә...е, г...мер, шәфк...ть, сөйк...мле, я...гын, бор...нгы, шөг..ль, гаҗ...п, г...мьсез, мөст...кыйль, к...нәфер, кагыйд..., дәг...ва, дәв...м, мәгълүм...т, орч..к, йолд...з, Бөг...лмә, җәмг...five

ә) Маш..на, ка..ш, реж..м, м..тор, юнә..ш, т..зек, к..пер, м..хан..к, л..тр, инж..н..р,кул..анма, каб...на, каб..ль, запа.., б..нз..н, яш..л, я..улык,п..чрак, г..р..ж,ху..а, авт..бус, аккумул..тор, аморт..затор, стаб..л..затор, стан..ия, св..тофор, сал..н, рул.., п..дал.., ном..р, һ..лак..т.

б) Мам..к, т..бә, в..ранда, әйб..р, бүр..нә, бл..к,асфал..т, мат..а, мәй...ан, авыр...ык, д..м, ш..реп, ...ава, ка..ка, га..ка, ка..ак, бал..ык, иш...к, так..а, т..мер, кала..., то..ак, җитешт..р..че, сын..у, кабел.., ташч..., к...рпеч, кат..ргы,ачк..ч, бу...у, акб..р, пыч..ы.

**Практик эш №10.** Аш - су өлкәсендә (ашханәләрдә, рестораннарда) эшләүчеләр нинди булырга тиеш? Тел чаралары ярдәмендә аларның образын тасвирлау.

**Практик эш №11.** Татар халкында киң таралган ризык төрләре, әзерләү ысуллары (презентация ясарга)

**Практик эш №12.** Берәр әдәби әсәрдән үз һөнәреңә кагылышлы текстны сайлап алырга, тексттагы образлы сурәтләү чараларын табарга

**Практик эш №13.** Саннар кулланып үзегезнең көндәлек режимыгыз турында инша язарга.

## 4. Промежуточная аттестация

**Промежуточная аттестация: дифференцированный зачёт**

Каждый студент, основываясь на изученные темы, делает презентацию «Моя будущая профессия».